**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Зур Сәрдек авыл җирлеге Башлыгы**
**карары**

**12 ноябрь 2020 ел** **№7**

**«Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Кара-Елга авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 25 ноябренә сәгать 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Кара Елга авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены*** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Кара-Елга авылы, Үзәк урам, 24 нче йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 5 һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән, 75 яшьтәге һәм аннан да өлкәнрәк ялгыз пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Кара-Елга урамнары юлларын вак таш җәеп төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Кара-Елга авылына керү һәм чыгу урынында видеокамералар урнаштыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге Башлыгы: Ф. М. Фәттахов.

ОГРН 1021607753232
ИНН 1623001727